| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2019 Казан шәһәре № 10-127/кс

«Саба районы торак коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте өчен 2020-2024 елларга эчә торган суга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Саба районы торак коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте өчен, әлеге карарның 1 кушымтасына туры китереп, эчә торган суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Саба районы торак коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте, әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2020-2024 елларга эчә торган суга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Саба районы торак коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ачык

акционерлык җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.11.2019 № 10-127/кс карарына
1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Саба районы торак-коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга 2020-2024 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Саба муниципаль районы | | |
| 1 | «Саба районы торак-коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте* | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 28,11 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 29,23 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 29,23 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 29,46 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 29,46 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 30,91 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 30,91 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 31,19 |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 31,19 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 32,69 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.11.2019 № 10-127/кс карарына
2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Саба районы торак-коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күп тармаклы җитештерү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга 2020-2024 елларга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган су | 2020 | 7931,29 | 1 | - | 8,70 | 1,13 |
| | | 2021 | 8142,50 | 1 | - | 8,60 | 1,12 |
| | | 2022 | 8391,67 | 1 | - | 8,60 | 1,12 |
| | | 2023 | 8644,32 | 1 | - | 8,60 | 1,12 |
| | | 2024 | 8904,63 | 1 | - | 8,60 | 1,12 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге